КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 октябрь г.Казань № 886

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжск» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжск» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 25 июль, 365 нче, 2009 ел, 19 июнь, 406 нчы, 2010 ел, 12 апрель, 256 нчы, 2011 ел, 14 апрель, 295 нче, 2012 ел, 9 февраль, 93 нче, 2012 ел, 2 май, 349 нчы, 2015 ел, 15 апрель, 253 нче, 2015 ел, 5 сентябрь, 637 нче, 2016 ел, 11 июнь, 398 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче, 2019 ел, 17 октябрь, 930 нчы, 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче, 2022 ел, 22 февраль, 152 нче, 2022 ел, 28 июль, 723 нче, 2023 ел, 22 март, 318 нче, 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы, 2024 ел, 19 август, 670 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 15 октябрь, 886 нчы
карары редакциясендә)

Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы (алга таба - тыюлык) төбәк әһәмиятендәге махсус саклanылучы табигать территориясе Зөя елгасы, Куйбышев сусаклагычының Свияжск култыгы һәм аның янәшәсендәге тугайлар участоклары табигый һәм ясалма экосистемаларын, промысел һәм сирәк төрдәге балыклар запасларын, уникаль табигый ландшафтны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу максатында төзелгән.

Тыюлык Татарстан Республикасының Зеленодольск һәм Югары Ослан муниципаль районнарында төзелгән, аның гомуми мәйданы 12 552,56 гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында.

1.4. Тыюлыкка йөкләнгән бурычлар нигезендә, шулай ук тыюлык эшчәнлегенә идарә итү максатларында функцияләрне гамәлгә ашыру өчен Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе тыюлык администрациясе төзелә.

1.5. Тыюлык чикләре һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы эшчәнлеген башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

II. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары:

биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклаnыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

## III. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча Дәүләт комитетының функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларны файдалану өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).

## IV. Тыюлыкны махсус саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

яңа торак пунктлар, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләр төзү, шул исәптән торак пунктларның, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләренең гамәлдәге чикләрен киңәйтү;

капиталь төзелеш объектларын, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү өчен, шулай ук бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өчен җир кишәрлекләрен бирү һәм барлыкка китерү (гамәлдәге торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә җир кишәрлекләрен бирүдән һәм барлыкка китерүдән, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктыдагы өченче абзацында каралган очраклардан тыш);

биналар, төзелмәләр, корылмалар, линия объектлары, инженерлык һәм техник коммуникацияләр төзү (торак пунктлар чикләрендә, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә мондый төзелеш очракларыннан, әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклардан тыш);

автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләреннән тыш юу;

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнүне һәм аларның яраклылыгын бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнүне үткәрү (әлеге эшчәнлекне тыюлык булдырылганга кадәр бирелгән лицензияләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары нигезендә гамәлгә ашырудан тыш);

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын уздыру очракларыннан тыш); урманнарны саклау, яклау һәм яңадан җитештерү; табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклау һәм торгызу максатларында; гражданнар куркынычсызлыгын тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларны саклау зоналары киңлеген саклау буенча, линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча һәм яңа линия объектларын төзегәндә;

1 апрельдән 31 июльгә кадәр бала чыгару-оя кору чорында кисүләр үткәрү;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карны туплау, торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендәге материалларны, грунтларны, карны туплаудан тыш;

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

туфрак катламын бозу, җир эшләрен башкару, моңа торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакча ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә туфрак катламын бозу, җир эшләрен башкару очраклары керми; урманнарны, авыл хуҗалыгы чараларын янгынга каршы төзекләндерү, фәнни тикшеренүләр уздыру, линия объектларын эксплуатацияләү, фәнни тикшеренүләр уздыру чараларын башкару, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктының икенче абзацы нигезендә рөхсәт ителә торган объектлар төзүгә бәйле очраклардан тыш;

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (хайваннар дөньясы объектларын фәнни максатларда, һәвәскәр һәм спорт аучылыгы максатларында файдаланудан, аларның санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

промысел аучылыгы;

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

кушымта нигезендә чикләрендә механик транспорт чаралары, мототранспорт чаралары, аз үлчәмле үзйөрешле суднолар йөрү һәм туктап тору, торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә механик транспорт чаралары йөрү һәм туктап торудан тыш; «Ял» коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәте һәм аңа гомуми файдалану юлыннан килү, шулай ук механик транспорт чаралары, юлсыз йөри торган мототранспорт чаралары, махсуслаштырылган техника, аз үлчәмле үзйөрешле суднолар йөрү һәм туктап тору:

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына һәм инженерлык-техник коммуникацияләргә хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, фәнни тикшеренүләрне үткәрү, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

тыюлыктагы табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, тыюлык территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.2. Тыюлык территориясендә, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; капиталь төзелеш объектлары, гидротехник корылмалар, инженер-техник коммуникацияләр, линия объектларын тыюлыкның чигеннән читтә урнаштыру вариантлары булмаган очракта әлеге яңа объектларны төзү; капиталь төзелеш объектларын, гидротехник корылмаларны, инженерлык һәм техник коммуникацияләрне һәм линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм әлегрәк төзелгәннәрен ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас

объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик кыр эшләрен башкару;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

төбәк геологиясен өйрәнү;

печән чабу, мал-туар көтү;

умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру.

4.3. Тыюлык территориясендә хуҗалык эшчәнлеге бу Нигезләмәгә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләренә таянып гамәлгә ашырыла.

## V. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

5.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

төп эшчәнлек төрләре:

үсемлекчелек (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.1);*

бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.2*);

яшелчәчелек (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.3*);

тонлаштырылган, дару, чәчәк культураларын үстерү (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләре чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.4*);

бакчачылык (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.5*);

терлекчелек (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.8*);

кошчылык (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.10*);

* Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

умартачылык (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.16*);

питомниклар (торак пунктлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән җирләрдә) (1.17*);

печән чабу (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.19*);

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.20*);

индивидуаль торак төзелеше өчен (торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакча ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә) (2.1*);

шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару өчен (торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакча ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә) (2.2*);

коммуналь хезмәтләр күрсәтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (3.1.1*);

фәнни тикшеренүләр үткәрү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (3.9.2*);

табигатьне танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

аучылык һәм балыкчылык (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.3*);

элемтә (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.8*);

табигать территорияләрен саклау (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

агач әзерләү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (10.1*);

урман плантацияләре (Дәүләт комитеты белән килештереп) (10.2*).

су объектларыннан гомуми файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.1*);

су объектларыннан махсус файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.2*);

гидротехник корылмалар (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.3*);

территорияне төзекләндерү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (12.0.2*);

яшелчәчелек алып бару (торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакча ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә) (13.1*);

бакчачылык алып бару (торак пунктларның һәм коммерциягә карамаган бакча ширкәтләренең гамәлдәге чикләрендә) (13.2*).

эшчәнлекнең ярдәмче төрләре:

автомобиль юлларын урнаштыру (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.2.1*);

торба үткәргеч транспорт (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.5*).

## VI. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

6.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик биеклеге – ике кат;

җир кишәрлеге чикләрендә йорт салу проценты – иң күбе 50 процент.